ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН БӘРӘСКӘ АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

НИЖНЕБЕРЕСКИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422743 Республика Татарстан Атнинский район с. Нижняя Береске Тел. 3-34-03

"17" август 2022 ел № 18

# КАРАР

Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Түбән Бәрәскә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында " 2020 елның 25 мартындагы 6 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 нче номерлы "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында" гы карары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 25 мартындагы 6 нчы номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Түбән Бәрәскә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә" түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорда нисбәте белән характерлана";

1.2. 12 пунктның 2 абзацында "дәүләт (муниципаль) программаларының структур элементлары турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 пунктта "муниципаль программаларның структур элементлары" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.